ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ

Аксубай муниципаль районы
**муниципаль беремлеге**
423072 Иске Тимошка
Авылы Ленина урамы, 2'
тел. 884344 4-53-40

РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН

**Аксубаевский муниципальный район муниципальное образование**
423072 с.Старое Тимошкино
улица Ленина, 27
тел. 884344 4-53-40

ИСКЕ ТИМОШКИНО АВЫЛ ЖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ

---

# КАРАР

№ 3 05.11. 2021ел

«Аксубай муниципаль районы Иске Тимошкино авыл җирлегенең Иске Тимошкино торак пунктында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләү турында»

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 06.10.2003 ел, № 131-ФЗ Федераль законның 25.1, 56 статьясы, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 28.07.2004 ел, № 45-ТРЗ Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Аксубай муниципаль районы «Иске Тимошкино авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставының 22 статьясы нигезендә КАРАР БИРӘМ:

1. Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы Иске Тимошкино авыл җирлегенең Иске Тимошкино авылында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын 2021 елның 16 ноябрендә 14 сәгать 00 минутта билгеләргә.

2. Гражданнар җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга:

«2022 елда Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы Иске Тимошкино авыл җирлеге Иске Тимошкино авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган торучыдан, I төркем инвалидларыннан, Бөек Ватан сугышы ветераннарыннан һәм көндезге формада белем алучы студентлардан тыш, 500 сум күләмендә үзара салым кертүегез белән һәм җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча юнәлдерү белән, Сез килешәсезме?:

**1. Җирлекнең торак пунктлары чикләрендә җирле әһәмияттәге автомобиль юлларына карата юл эшчәнлеге:**

**- Иске Тимошкино авылы эчендәге юлларны кышкы чорда карап тоту (килешү буенча эшләр өчен түләү, кардан чистарту);**

**- поселок эчендәге юлларны ремонтлау (вак таш сатып алу Щ(ПС)), грунт һәм вак ташны күтәрү, чәчелү һәм тигезләү (килешү буенча эшләр һәм хезмәтләр өчен түләү);**

**2. Каты коммуналь калдыкларны җыю (шул исәптән аерым җыю) һәм транспортлау эшчәнлеген оештыруда катнашу:**
**- контейнер мәйданчыклары төзү, (төзелеш материаллары сатып алу, килешү буенча эшләр һәм хезмәтләр өчен түләү);**

**3. Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән вәкаләтләр чикләрендә җирлек чикләрендә халыкны су белән тәэмин итү, агынты суларны чыгару, халыкны ягулык белән тәэмин итүне оештыру:**
**- Елга аръягы урамында су торбасын алыштыру**

**4. Торак пунктлар чикләрендә беренчел янгын куркынычсызлыгы чараларын тәэмин итү (ягулык-майлау материаллары, запас частьләр сатып алу, янгын сүндерү машинасын йөртүчеләрнең хезмәт хакы)**

**5. Җирлек территориясен төзекләндерүне оештыру:**
**- урам буенча сулыкларны чистарту (эшләр башкару, килешү буенча түләү).**

«РИЗА» «КАРШЫ»

3. Авыл мәдәният йорты янында гражданнар җыенын Татарстан Республикасы Аксубай районы Иске Тимошкино авылы, Ленин урамы, 27 йорт адресы буенча үткәрергә.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга, авыл җирлегендә яшәүчеләр күпләп җыела торган урыннарда, стендларда һәм игъланнар такталарында элү юлы белән халыкка игълан итәргә, шулай ук Аксубай муниципаль районының рәсми сайтында (http://aksubayevo.tatarstan.ru) урнаштырырга.

5.Әлеге карар басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Аксубай муниципаль районы
Иске Тимошкино авыл җирлеге башлыгы: П.А.Мулеева